Республика Татарстан
Совет Альметьевского сельского поселения Сармановского муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге советы

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2016ел, 25 январь. № 6

Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., Әлмәт авыл җирлеге Уставының 11 ст., Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Советы карар итә.:

1."2016 елда Әлмәт авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешегә 200 сум күләмендә үзара салым акчасын кертүгә, I төркем инвалидларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчалардан тыш, сез риза буласызмы?:

1). Җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру.

2). Җирлек территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спорт үсеше өчен шартлар булдыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру.

3). Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктырту, территорияне яшелләндерүне дә кертеп).

4). Җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру.

5). Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру.

6). Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген оештыру..

« ЮК» «ӘЙЕ».

2. Әлеге карар мәгълүмат стендларында һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге
Советы Рәисе Д.Ә. Газизов.